ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының алтынчы утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы алтынчы утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы квалификация комиссиясе әгъзаларын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкилләрен сайлап кую турында.
4. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 33-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 32-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $53^{1}$ статьясының гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм 2025 елда Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү хакында» 25-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы территориясендә региональ инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда салым салуның аерым мәсьәләләрен җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 28-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым

түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 27-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 34-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 36-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Татарстан Республикасы Җир кодексының $32^{1}$ статьясына үзгәреш кертү турында» 26-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

12. «Татарстан Республикасында хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенең 6 пунктын һәм 2 өлешенең 1 пунктын үз көчен югалткан дип тану хакында» 29-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең җир кишәрлекләрен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 19-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 37-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

15. «Махсус хәрби операциядә катнашучы затларга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм өлкәсендә мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 30-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 22 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 31-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы

Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 35-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. Татарстан Республикасында гражданнар сәламәтлеге торышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады.

19. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2024 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисап.

20. 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планы проекты турында.

21. 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Россия Федерациясе субъектлары, башка дәүләтләр парламентлары һәм халыкара парламент оешмалары белән хезмәттәшлегенең якынча планы турында.

22. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты составындагы үзгәреш турында.

23. Сәяси репрессияләрнең реабилитацияләнгән корбаннары хокукларын торгызу буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында.

24. «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 780703-8 номерлы федераль закон проекты турында (каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) булдыруны һәм карап тотуны хокукый җайга салу өлешендә).

25. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 775871-8 номерлы федераль закон проекты хакында (күпфатирлы йортларда лифт җайланмаларына техник хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча).

26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 764329-8 номерлы федераль закон проекты турында (һава транспортында йөртү шартнамәсе шартлары хакында мәгълүмат урнаштырмаган өчен җаваплылык билгеләү өлешендә).

27. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 770483-8 номерлы федераль закон проекты турында (нацистлар атрибутикасын яисә символикасын пропагандалаган йә халык алдында күрсәткән өчен административ җаваплылыкны көчәйтү хакында).

28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 771606-8 номерлы федераль закон проекты турында (Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының $15.12^1$ статьясында каралган административ хокук бозулар хакындагы эшләрне караучы органнар исемлеген тулыландыру өлешендә).

29. «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә һәм «Башкару эше турында» Федераль законның 12 һәм 30 статьяларына

үзгәрешләр кертү хакында» 782260-8 номерлы федераль закон проекты турында (салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычын судтан тыш тартып алу тәртибе хакында).

30. «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның $25^{1}$ статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Владимир өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

31. «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чуваш Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

32. «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» Федераль законның 12 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Мордовия Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

33. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында миграция сәясәте өлкәсендә алып барыла торган эш турында».

34. 2024 елда җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.

35. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 23 декабре
№ 129-VII ДС